ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
II СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
II ЧАКЫРЫЛЫШ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июль, 2015 ел № 41/4

2016 елга, 2017 һәм 2018 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19, 28 маддәләренә, Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 санлы Карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2016 елга, 2017 һәм 2018 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү көнен 2016 елның 9 ноябренә, үткәрү вакытын 14 сәгатькә тәгаенләргә, гавами тыңлауларны үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасын (Х.Туфан проспекты, 23 йорт), 400 залны билгеләргә.

2. 2016 елга, 2017 һәм 2018 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү буенча комиссия составын кушымтадагыча расларга.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының икътисадый сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазифаларын башкаручы Ф.И. Андреева

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
41/4 нче Карарына
кушымта
23 июль, 2015 ел

2016 елга, 2017 һәм 2018 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Галиәкбәрова Әлфинур Азат кызы | - Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы, комиссия рәисе; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | - Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы; |
| Сәгыйдуллна Ирина Алексеевна | - Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары; |
| Мисбахова Ландыш Тәбрис кызы | - Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары, бюджет бүлеге башлыгы; |
| Галиева Ләйсән Ринат кызы | - Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет сәясәте бүлеге башлыгы. |